ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 августында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4, № 7 (I өлеш); 2016, № 1 – 2; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27, (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) җирле вакыт белән 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр, Федераль законның 16 статьясындагы 9 пунктының беренче абзацында каралган очракларда алкоголь продукциясен ваклап сатудан тыш;»;

б) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) күпфатирлы йортларда һәм (яисә) алар янәшәсендәге территорияләрдә урнашкан, килүчеләргә хезмәт күрсәтү залының гомуми мәйданы 50 квадрат метрдан ким булган җәмәгать туклануы объектларында, әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш.

Килүчеләргә хезмәт күрсәтү залы мәйданы дигәндә җәмәгать туклануы объектының әзер кулинария продукциясен, кондитер әйберләрне һәм (яисә) сатып алына торган товарларны куллану өчен билгеләнгән махсус җиһазланган урыннар мәйданы аңлашыла, ул инвентарьлаштыру һәм хокук билгеләү документлары нигезендә билгеләнә.

Күпфатирлы йортлар янәшәсендәге территорияләрнең чикләре Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен исәпкә алып билгеләнә;»;

г) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) халык саны 500 мең кешедән артык булган монопрофильле муниципаль берәмлекләр (моношәһәрләр) территориясендә күпфатирлы йортларда һәм (яисә) алар янәшәсендәге территорияләрдә урнашкан, килүчеләргә хезмәт күрсәтү залының гомуми мәйданы 100 квадрат метрдан ким булган җәмәгать туклануы объектларында;»;

д) 5 пунктта «ресторан», «кафе» типларына кертелгән җәмәгать туклануы объектларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) $2^1$ һәм 3 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы оешмалар әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр бирелгән җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуга лицензия нигезендә күрсәтелгән эшчәнлекне күпфатирлы йортларда һәм (яисә) алар янәшәсендәге территорияләрдә урнашкан, килүчеләргә хезмәт күрсәтү залының гомуми мәйданы «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезендә билгеләнгән җәмәгать туклануы объектларында мондый лицензиянең гамәлдә булу срогы беткәнче башкарырга хокуклы.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 04 сентябрь
№ 51-ТРЗ